Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР

2021 елның 8 феврале № 6/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Ислəй авыл җирлеге Советының
2019 елның 5 июнендəге 62/1 номерлы
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районының «Ислəй авыл җирлеге»
муниципаль берəмлегендə муниципаль хезмəт
турында» карарына үзгəрешлəр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дəүлəт граждан хезмəте турында» Татарстан Республикасы Законына һəм муниципаль хезмəт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгəрешлəр кертү хакында» 2020 елның 26 декабрендəге 96-ТРЗ номерлы һəм «Муниципаль хезмəт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясына үзгəреш кертү хакында» 2020 елның 21 июлендəге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендə, Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлегендə муниципаль хезмəт турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2019 елның 5 июнендəге 62/1 номерлы Ислəй авыл җирлеге советы карары белəн расланган Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлегендə муниципаль хезмəт турында нигезлəмəгə түбəндəге үзгəрешлəрне кертергə:

1.1. 6 статьяның 22 пунктын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«22. Муниципаль хезмəткəргə класслы чин бирү турында белешмəлəр шəхси эшкə һəм хезмəт кенəгəсенə (булган очракта) кертелə.»;

1.2. 11 статьяның 5 пунктын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«5. Җирле үзидарə органы, муниципаль берəмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитəкчесе булган муниципаль хезмəткəр, əлеге муниципаль хезмəткəр урынбасары, мəнфəгатьлəр конфликтын булдырмау максатларында, əлеге җирле үзидарəнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берəмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа билəгəн чорда муниципаль хезмəткəрлəрнең мəнфəгатьлəрен тəкъдим итə алмый.»;

1.3. 13 статьяның 3 пунктында:

4 пунктчаны түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«4) хезмəт кенəгəсен һəм (яисə) хезмəт эшчəнлеге турында белешмəлəрне, хезмəт шартнамəсе (контракт) беренче тапкыр төзелгəн очраклардан тыш, законнарда билгелəнгəн тəртиптə рəсмилəштерелгəн;»

6 пунктчада «Мəҗбүри пенсия иминлəштерүенең иминият таныклыгы» сүзлəрен «индивидуаль (шəхсилəштерелгəн) исəпкə алу системасында теркəлүне раслый торган документ» сүзлəренə алмаштырырга;

1.4. 20 статьяның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында, Россия Федерациясе Пенсия фонды мәгълүмат ресурсларында саклау өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм авыл җирлеге халкының массакүләм җыелу урыннарында, игълан итү стендларында һәм такталарында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Исләй авыл җирлеге
башлыгы В.П. Чернышев